СОВЕТ МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи,
422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы,
422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ | КАРАР

28.11.2025 | №3-22

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

с. Русское Макулово

**Торак пункт территориясенең шушы өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрү өчен Макыл авыл җирлеге составына керүче Рус Макылы авылы торак пункты территориясенең бер өлеше чикләрен билгеләү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районының
Макыл авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Гражданнар яшәгән түбәндәге территорияләр чикләрендә торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрү өчен территориянең бер өлеше чикләрен билгеләргә:

Рус Макылы авылы:

Заречная урамында №2А, 3, №5, №6, №8, №9, №11, №20, №22, №31 торак йортлар.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Макыл авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни мәсьәләләр, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

3. Әлеге карарны Югары Ослан авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Макыл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Макыл авыл җирлеге  башлыгы — П.Е. Карпухин